# Нәсыйхәт

җомга
23
декабрь
2011 №11

**Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән**
**Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы**

# Булдырасың, Ильяс!

**Авылдашым, Уразбахты авылы егете Ильяс Халиков исеме мамадышлыларга яхшы таныш. Мәктәптә укыганда ук районның данлыклы көрәшчесе иде ул.**

.....................................
ФИРАЯ МИНГАЛИЕВА

Районыбызның иң матур җирендә урнашкан Уразбахты авылында туган җырчы, галимебез белән без чын күңелдән горурланабыз. Авылның җиләкле таулары, инешләре, күлләре, матур табигате җыргамоңга сәләтне дә биргән. Үз шигырьләренә чыгарган җырлары да байтак. “Бәхет мизгелләре”, “Әниемнең туган көнендә” исемлеләре туганы Резеда Кадыйрова репертуарына да кергән. Шушы араларда Россия ислам университетының актлар залында татар телендә мөнәҗәтләр-нашидлар (дини җырлар) башкаручы якташыбыз Ильяс Халиковның беренче клибы “Шөкер, Аллам” тәкъдим ителде. Җырларына көен автор-башкаручы үзе яза, ә шигырьләрен–җәмәгате Нурфия. “Укытучы буларак, мин мөнәҗәтләр яшь буынны тәрбияләүдә, чисталык, пакьлек, яхшылыкны пропагандалауда көчле чара булып торганын аңлыйм. Алар мөселман дәгъватының бер өлеше,”–ди Ильяс.



Якын арада ул үзенең беренче альбомын чыгарырга җыена. Авыл мәктәбендә укыганда ук Ильяс күп кенә концертларда катнаша, җырлар иҗат итә иде. Казан дәүләт педагогия университетында укыган елларында “Студентлар язы–ягымлы яз” фестиваленең халык уен кораллары номинациясендә чыгыш ясап, дипломга лаек булды. Бүгенге көндә авылдашым Россия Ислам университетында педагогика һәм психология укыта. Шиһабетдин Мәрҗәни исемендәге тарих институтында аспирантура тәмамлаган. Педагогика фәннәре галиме Шамил Җәләлиев җитәкчелегендә кандидатлык диссертациясе әзерләгән. Татарстан Фәннәр Академиясенең Ш.Мәрҗәни исемендәге Тарих институты, Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге Ильяс Халиковның “Татар халкының педагогик фикере үсешендә ислам кыйммәтләре” исемле китабын бастырып чыгарды. Ул якташыбызның диссертациясе буенча эшләнгән. Китап педагогик фикер тарихы укыту-тәрбия өлкәсендә эшләүчеләргә һәм киң күләм укучыларга тәкъдим ителә. Киләчәккә планнары белән кызыксынгач: “Иң мөһиме–белемнәремне яшьләрне тәрбияләү өлкәсендә куллану”,–ди Ильяс. Җәмәгате Нурфия әниемнең туган авылы Кукмара районы Бурсык-Елга авылыннан. Кунакка кайткач әнием янына керми китми. Аларның берсеннән-берсе гүзәл ике кызлары бар. Гаиләләре белән бишвакыт намазны калдырмыйлар. Кызлары да әти-әнисе белән бергә намаз укый. Киләчәктә дә бу гаиләгә шулай ислам диннәрен куәтләп яшәүләрен, иҗади уңышлар теләп калам.

## Яңалыклар

**ИНВАЛИДЛАР УНКӨНЛЕГЕ ТӘМАМЛАНДЫ**

Декада дәверендә мәдрәсә көченнән килгәнчә чикләнгән мөмкинчелеккә ия булган кешеләргә ярдәм итү акциясе оештырды. Үткәрелгән чарада мәдрәсә хезмәткәрләре катнашты. Алар инвалидларга ашамлыклардан торган пакетлар өләштеләр. Мәдрәсә мондый чараларны киләчәктә дә үткәрергә планлаштыра.

**СЕРТИФИКАТКА ИЯ**

Мәдрәсә мөгаллиме Ирек хәзрәт Нуриев Мәскәүдә үткәрелгән белемне арттыру курсларында булып кайтты. Әлеге курслар Мәскәү Ислам университетында үткәрелде һәм 72 уку сәгатеннән торды. Биредә күренекле ислам галимнәре лекцияләр укыдылар һәм тәрбия ысулларына кагылышлы практик дәресләр бирделәр. Курсларны уңышлы үткән укучыларга сертификат бирелде.

**УКУЧЫЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУ**

Район мөхтәсибе Илһам хәзрәт һәм мәдрәсә директоры Габдрахман хәзрәт район авылларына йөрүне дәвам итәләр. 11 нче декабрь көнне алар Олыяз авылында яшьләр белән очраштылар. Ислам диненә кагылышлы вәгазьнәсыйхәт сөйләделәр, дини гыйлемнең әһәмиятлеге турында сүз алып бардылар. 15 нче декабрь көнне алар Түбән Яке мәктәбендә укучылар һәм укытучылар белән очраштылар. Бүгенге вәзгыятьтә дин дәресләренең актуальлеге турында сүз алыштылар.

**БЕРЕНЧЕ УРЫН ЯУЛАДЫ**

17 нче декабрь көнне Казанда Рәсәй ислам университетында үткән мөселман хатын-кызлары арасында үткән бәйгедә Мамадыш мәдрәсәсе шәкерте Гүзәлия ханым беренче урынны яулады. “Әлбәттә җиңү җиңел бирелмәде, әмма шундый зур урынны яуларга Аллаһы Тәгалә үзе булышты”,–ди Гүзәлия ханым.

**КЫШКЫ КАНИКУЛНЫ МӘДРӘСӘДӘ**

Мәчеткә актив йөргән район авыллары балалары кышкы каникулларын Мамадыш мәдрәсәсендә үткәрә алачаклар. 2 нче гыйнвардан 9нчы гыйнварга кадәр аларга дини дәресләр укытылачак һәм актив ял оештырылачак.

# ДӨНЬЯ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

**“ИМАН” НӘШРИЯТЫ “АПАНАЙ МӘЧЕТЕНЕҢ ЯҢАРЫШЫ” ДИГӘН КИТАП БАСТЫРДЫ**

«Иман» нәшрияты «Апанай мәчетенең яңарышы» китабын дөньяга чыгарды.

Әлеге китапның бастырылуы Казанның Апанай мәчетен торгызу белән бәйле. Анда торгызу-ремонтлау эшләре барышы хакында бәян ителә. Китапны бастыруга, соңгы елларда мәчетне төзекләндерү эшләре белән мәшгуль булган, Әхмәд хәзрәт Сабиров һәм Вәлиулла хәзрәт Якупов әзерләгән, дип хәбәр итә Islamrt.ru.

«Апанай мәчетенең яңарышы» китабының күләме 20 битне тәшкил итә.

**КАЗАНДА БАРЫ ТИК 10 КАФЕ ҺӘМ РЕСТОРАН ТАТАРСТАН ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕНЕҢ “ХӘЛӘЛ” СТАНДАРТЫ КОМИТЕТЫ КОНТРОЛЬЛЕГЕНДӘ**

Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандартлары Комитеты быел 9 кафе һәм 1 ресторанга сертификат бирде. Шул рәвешле, Комитет аларда хәләл ризык иконлекне гарантияли. Һәрбер кафега яки ресторанга Комитет тарафыннан, әзерләнәсе ризыклары хәләл, дигән «Шәһадәтнамә» тапшырылган. Шулай ук кафеда әзерләнәсе ризык өчен азык-төлекләр китерүчеләр дә катгый контрольдә тотыла.

Соңгы арада башкалабызда бик күп кафелар, ресторannар үзләрен хәләл дип тәкъдим итеп, хәләл меню китерә. Ләкин, кызганычка, бу кафе, ресторannарга китерелгән азык-төлекне берәү дә үз контрольлегенә алмый. Шуңа күрә, Комитет җәмәгатьчелеккә игътибарлы булырга һәм Комитеттан тапшырылган «Шәһадәтнамә»не күрсәтүләрен таләп итәргә куша. Түбәндә хәләл-менюга ия булып, шәригать кануннары буенча әзерләнгән ризыкны гына тәкъдим итүче ресторан һәм кафелар исемлеге китерелгән:

«Азу» кафесы, татар ашханәсе; «Рәйхан» кафесы, Аурупа һәм Япон ашханәсе; «Дархан» кафесы, үзбәк ашханәсе; «Сабрина» кафесы, шәрык ашханәсе; «Roll-house» кафесы, Япон ашханәсе; «Япон ашханәсе» кафесы; «Киш-миш» кафесы, шәрык ашханәсе; «Рубаи» рестораны, үзбәк ашханәсе чәйханәсе; «Dream кафе», Аурупа һәм Япон ашханәсе.

**«МӨХӘММӘД ПӘЙГАМБӘР – ҖИР ЙӨЗЕНӘ РӘХМӘТ ӨЧЕН ҖИБӘРЕЛГӘН» ДИГӘН БӨТЕНДӨНЬЯ VI ШИГЫРЬ БӘЙГЕСЕ СТАРТ АЛДЫ**

Мөфтиләр Советының Социаль-хәйрия һәм рухи-агарту эшчәнлеге департаменты «Мөхәммәд пәйгамбәр — җир йөзенә рәхмәт өчен җибәрелгән» дигән Бөтендөнья VI шигырь бәйгесе үткәрү хакында хәбәр итте. Бәйгегә автордан пәйгамбәребезнең (с.г.в.) тормышына кагылган рус һәм татар телендәге әсәрләр кабул ителә. Бәйгенең шартлары белән танышу һәм ошаган хезмәткә тавыш бирүне ( 2012 елның 1 нән 10 февраленә кадәр) mavlid-konkurs.ru. рәсми сайты аша башкарырга була.

1 нче урын яулаучыга 20 мең сум, 2 урынга 15 мең сум, 3 урынга ия булучыга 10 мең сум акча биреләчәк. Бәйгедә катнашу өчен 2011 елның 5 декабреннән 2012 елның 5 февраленә кадәр бәйгегә дигән эшне һәм гариза бирергә кирәк. Аны түбәндәге ысуллар белән эшләргә мөмкин:

mavlidkonkurs@mail.ru электрон адресына хат җибәрү («Шигырьләр бәйгесе» нә теманы күрсәтеп);

129090, Мәскәү шәһәре, Выползов, 7 адресына хат язу («Россия мөфтиләре Советы, Шигырьләр бәйгесе» дигән күрсәтү белән).

Катнашучының хатында:

бәйгегә дигән материал — бәйге шартларына туры килә торган шигырь;

бәйгедә катнашу өчен гариза (басма турында белешмә); автор турында белешмә: кыскача гына биографиясе, өй адресы (почта индексы белән), контакт телефоны (шәһәр коды белән), электрон почта адресы булырга тиеш.

Бәйгенең нәтиҗәләре 2012 елның февралендә билгеле булачак. Өстәмә мәгълүматны mavlid-konkurs.ru сайтында һәм 8-926-247-93-06 яки (495) 684-31-98 телефоннары аша белергә була, дип хәбәр итә islam.ru.

# Яулыклы кыз...

**Һәрвакыт урамга чыгар алдыннан ул көзгә каршына килә. Әлбәттә бизәнер өчен түгел... Ул үзенең Аллаһы Тәгалә биргән матурлыгын башкалар алдында модага куярга теләмәү максатыннан.**

**Кемнәрдер хиджабны шунда ук кия башлый. Ә кемгәдер кияр өчен күпмедер вакыт, әзерлек кирәк. Әчке дөньябызда сугыш башлана: кеше сүзенә карап кимәскә, яисә Аллаһ каршысында булган бурычыбызны үтәргә. Мәркәзебез Казанда мөслимә туташларны еш очратырга була. Бер-берсенә якында гына урнашкан матур мәчетләребез моңлы азан тавышы белән үзләренә чакыралар. Бу дөньяда һәр кешенең язмышы төрлечә үрелә. Шуның кебек безнең мөслимәләребезнең дә яулык яба башлаулары, хиджаб кию тарихлары төрлечә. Мин сораштыру үткәргән кызлар бәтенесе дә “Мөхәммәдия” шәкертләре. Әссәләмүгаләйкүм кызлар! Мин сезне кешеләр еш борчый торган сорау белән “борчып” алам. Кайчан исламның фарызларын үти башладыгыз? Ничек һәм нинди ситуациядән соң яулык яптыгыз?**

**Юлия, 24яшь. Казахстан:**

- Ассалямуалейкум! Миңа 22 яшь иде. Элек муеныма урап йөргән яулыгымны башыма яптым, әлхәмдүлилләх! Ислам дине күп еллар буе йөрәгемне дулкынландырды. Мөселман кызларына карап соклана идем. Хәзер үзем дә алардан ким түгел дип саныйм. Исламны аңлап, төшенеп, күп дини китаплар укып, динебезнең төп арканнарын үти башладым...

**Луиза, 18 яшь Арча районы:**

- Намазны мин 4-5 класcларда укый башладым. Иң беренче дингә әтиебез кереп китте. Арчадагы мәчеткә йөри башлады ( аны анда җизни чакырды). Бездә дә кызык булып китте, аңа ияредек. Иң беренче укытучыларым Ильяс остаз һәм Сания апа булдылар. “Мөгаллим сәни”дән хәрефләр өйрәнә башладым. Китапның уңнан ачылып, гарәп телендә сүзләрнең уңнан укылуына аптырадым. Шулай бергәләп, өйдә әти янына басып, намаз укый башладык. Соңрак әни дә безгә кушылды. Ә яулыкны 10 класста яптым. Моңа кадәр мәчеткә барганда гына ябарга кирәк дип уйлый идем, фарызлыгын белмәдем. Менә хәзер “Мөхәммәдия”дә көндезге бүлектә, РИУ да читтән торып укыйм, Әлхәмдүлилләх.

**Айгөл. Казан:**

-Мин хиджабны Аллаһ ризалыгы өчен кидем. Чөнки мөселман хатын-кызы балигълык яшенә җиткәч, үзенең гаурәт җирләрен каплап йөрергә тиеш. Гаурәт җирләрне каплап, яулык ябу фарыз икәнлеген законыбыз булган Коръән Кәримнең “Нур” сүрәсе 31нче аятеннән укып белә алабыз. Хәдисләрдә дә бу турыда әйтелә. Хиджаб кигәннән соң мин үземне шундый уңайлы хис итәм, җаным да тыныч. Үземне бәләкәй чагымдагы кебек, җил-яңгырдан саклаучы әниемнең кочагында тоям. Бөтен кеше дә шушы бәхетне аңласа, ничек шәп булыр иде.

Мөслимәләр! Аллаһ барчаларыбызга да авырлыкларга каршы торырга көч бирсен, ике дөнья бәхете насыйп итсен. Ә инде кем әле яулык япмаган аларга туры юл, кыюлык һәм алга!

**(Ахыры 4нче биттә)**

# Кәсебенең бәрәкәте нидә?

Пәйгамбәребездән: "Нинди кәсеп иң хәерле?"- дип сорадылар. Ул: "Кешенең үз кулы белән хәләл юл белән башкарылган кәсебе",- дип җавап бирде. Бүгенге вәзгыятьтә дә бу мәсьәлә үз актуальлеген югалтмый. Чөнки бүгенге көндә бик күп кешеләр кәсеп белән, сату итү белән шөгыльләнә. Әмма, ни кызганыч, аларның күбесе ислам кыйммәтләрен читтә калдырып, аларга битараф булып, Аллаһ тыйган рәвештә эшләрен алып баралар. Алар өчен төп максат, керемне мөмкин кадәр күбрәк кертү. Бу хезмәтләрендә максатларына ирешү өчен күбесе зур гөнаһлардан да чиркан-мый. Мондый караш белән эш итү исә җәмгыятькә дә зур зыян сала. Күп кешеләр алдана, рәнҗетелә, ихтыяҗлары канәгатьләнмичә кала.

Шуңа күрә әлегедәй киеренкелекләр булмасын өчен ислам шәригатендә кәсепкә һәм икътисадый мәсьәләләргә кагылышлы бер төп принцип бар. Бар мал-мөлкәтнең дә төп хуҗасы - Аллаһы Раббыбыз. Шуңа күрә кеше, кем булуына карамасын, малны кулланганда да, аның белән кәсеп иткәндә дә аның төп идарәчесе булган Аллаһы Тәгаләнең таләпләренә туры китереп кулланырга бурычлы. Әгәр дә эшен шушы кысаларда алып барса, кәсепче хуҗасының ризалыгын ала, юк икән, ул гөнаһлы була һәм Раббысының шелтәсенә лаек була. Раббыбыз кәсебебездән риза булсын дисәк, аны ничек алып барырга кирәк? Бизнесыбыз уңышлы һәм бәрәкәтле булсын дисәк, без аны нинди әчкерсез принципларга нигезләргә тиешбез? Әлеге кагыйдәләрнең кайберләрен искәртеп үтик. Алар үзләре бик гади һәм элементар, әмма икенче яктан бик нәтиҗәле.

**БЕРЕНЧЕ КАГЫЙДӘ:** Кәсебебезне Аллаһтан куркып һәм ихластан башкару кирәк.

Ат-Тирмизидән риваять китерелә, Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм әйтте: Кыямәт көнендә барлык Аллаһтан курыкмаган һәм эшендә аңа ихласлы булмаган барлык кешеләр гөнаһлылар белән бергә кубарылырлар, Раббыларының ачуына дучар булырлар." Әбү Зәр Җөндүп бине Җөнәдә һәм Әбү Габдеррахман Мөгаз бине Җәбәл сүзләре буенча, Пәйгамбәр галәйһиссәләм әйткән: «Кайда гына булсаң да, Аллаһыдан курык, начар эштән соң аны сөртерлек яхшы гамәл кыл. Кешеләр белән мөнәсәбәтләрдә яхшы әхлаклы бул»

**ИКЕНЧЕ КАГЫЙДӘ:** Кәсебебезне Аллаһ кушкан рәвештә, шәригатькә муафыйк булган сурәттә башкару.

Абу Нугаймнан риваять ителә, Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм әйтте: "Адәм баласы Раббысыннан тәкъдир кылынган ризыгын алмыйча, бу дөньядан китмәс. Аллаһтан куркыгыз, аннан дога кылып хәерле ризык сорагыз. Аллаһтан булган малыгызның кичектерелеп килүе кәсебегезне хәрәмгә нигезләргә этәрмәсен. Дөреслектә бәрәкәтле ризык Аллаһка итәгать күрсәтеп кенә буладыр."

**ӨЧЕНЧЕ КАГЫЙДӘ:** Шәригатьчә кәсеп итү кагыйдәләрен өйрәнү. Үз вакытында икенче халиф булган Гомәр, аннан Аллаһы Тәгалә риза булсын, базарга чыгып андагы кайбер сатучыларны шелтәләп: "Безнең базарларда шәригатьчә кәсеп итүне өйрәнмәгән сатучыларга урын юк. Белегез әлеге кагыйдәләрне өйрәнмәүче риба ашаучылар сафына керә, Раббыбызның ачуына дучар була,"- дип әйтә иде.

**ДҮРТЕНЧЕ КАГЫЙДӘ:** Сәбәпләрне кылу. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм әйтте: "Көчле мөселман зәгыйфь мөселманга караганда Аллаһ каршында яхшырак һәм сөйкемлерәктер, әмма икесендә дә хәерлелектер. Сиңа файда китерә торган хезмәт белән шөгыльлән, кайгыларга бирешмә, Аллаһка тәвәккәллек кыл. Сиңа нинди дә булса күңелсез хәл ирешсә, әгәр дә бу эшне болай эшләсәм болай булыр иде,-дип әйтмә. "Әгәр дә", дигән сүзең шайтанга юл ача".

**БИШЕНЧЕ КАГЫЙДӘ:** Эшеңне Аллаһка карата булган гыйбадәтне калдырмыйча башкару. Аллаһ Тәгалә Коръәни Кәримдә болай диде: "Алыш - биреш итеп сәүдә эшләренә алынмый торган ирләр, аларны алдый алмады дөнья эшләре Аллаһ зекереннән, һәм намазлардан, һәм зәкәт бирүдән, алар күңелләр һәм күзләр тетрәгән Кыямәт көненең катылыгыннан куркалар". ("Нур" сүрәсе, 37 аять)

**АЛТЫНЧЫ КАГЫЙДӘ:** Кәсеп иткәндә шикле әйберләрдән ерак булу. Әбү Габдуллаһ Ногман бине Бәшир разыяллаһу ган-һү сөйләгән: «Мин Аллаһының Илчесенең болай дигәнен ишеттем: «Дөреслектә, хәләл дә билгеле; хәрам да билгеле. Алар арасында шикле нәрсәләр бар. Болар турында күп кешеләрнең төгәл фикере юк. Шикледән сакланучы динен һәм намусын саклау өчен аннан котыла. Шикле белән шөгыльләнүче хәрамны да кылуга киләчәк. Чөнки ул тыюлык янында көтү көтеп, көтүе менә-менә тыюлыкка керүче көтүчегә тиң. Һәр патшаның шундый тыюлыгы бар. Ә Ал-лаһының тыюлыгы – Аның кешеләргә хәрам кылган нәрсәләре. Дөреслектә, кеше тәнендә ит кисәге бар. Ул яхшы булса, бөтен тәнне дә яхшы итә. Начар булса, бөтен тән дә яраксызга чыга. Ул ит кисәге – йөрәк». (Бухари )

**ҖИДЕНЧЕ КАГЫЙДӘ:** Сабыр булу. Пәйгамбәр кызын сәламләргә һәм болай дип әйтергә боера:

«Дөреслектә, Аллаһ алган нәрсә дә, бүләк иткән нәрсә дә Аныкы. Ул (Аллаһ) һәр нәрсәгә билгеле бер вакыт билгеләгән. Шулай булгач, ул сабыр итсен һәм Аллаһының әҗеренә өметләнсен».

**СИГЕЗЕНЧЕ КАГЫЙДӘ:** Эштә тугры булу. «Кеше иртә белән йокыдан торганда аның бөтен әгъзалары телгә мөрәҗәгать итеп: «Безнең хакта Аллаһыдан курык. Чөнки без барыбыз да сиңа бәйле. Син тугры булсаң, без дә тугры булабыз. Син тугрылыктан тайпылсаң, без дә тайпылырбыз!» – дип әйтерләр».

**ТУГЫЗЫНЧЫ КАГЫЙДӘ:** Кәсеп иткәндә ялган антлар белән ант итмәү. Әбү Хөрәйрәдән риваять кылына ки, Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм әйтте: "Ант товарның сатылуына сәбәп була, әмма аның бәрәкәтен юкка чыгара"

**УНЫНЧЫ КАГЫЙДӘ:** Юмартлык күрсәтү һәм сәдака бирү.

Кайс ибн Әбү Гарзадан риваять ителә ки, Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм әйтте: "...Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм безнең тирәдән үтеп киткәндә ошбу сүзләрне әйтте: "Сату итүчеләр, дөреслектә сатуыгызга гөнаһ һәм шайтан керүчәндер, шуңа күрә кәсебегезне сәдака белән пакълагыз". (Абу Дауд, ат-Тирмизи)

**УНБЕРЕНЧЕ КАГЫЙДӘ:** Киметеп үлчәмәү. Аллаһ Тәгалә Коръәни Кәримдә болай диде: "Киметеп үлчәүчеләргә ни үкенеч, каты газаптыр". ("Киметеп үлчәүчеләр" сүрәсе 1 нче аять)

**УНИКЕНЧЕ КАГЫЙДӘ:** Рибаны (процент белән эш итүне) калдыру. Аллаһ Тәгалә Коръәни Кәримдә болай диде: "Аллаһ сәүдә эшләрен хәләл итте, риба эшләрен хәрам кылды."

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм әйтте: «Һәлакәткә илтүче җиде гөнаһны кылудан саклагыз!» Кешеләр: «Әй Аллаһының Илчесе, бу нинди гөнаһлар?» – дип сораганнар. Ул: «Аллаһыдан башка затка гыйбадәт кылу, сихер, хаксыз кеше үтерү, риба, ятимнәр малын ашау, һөҗүм көнендә артка чигенү, гыйффәтле мөэминә хатын-кызларны зина кылуда гаепләү» дип җавап биргән».

**УНӨЧЕНЧЕ КАГЫЙДӘ:** Вакытында зәкәт түләү. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Аларның малларыннан зәкәт садакаларын ал. Аның белән син аларны чистартырсың һәм эшләрен төзәтерсең».

**УНДҮРТЕНЧЕ КАГЫЙДӘ:** Өстәмә (нәфел) гыйбадәтләр кылу. Пәйгамбәр галәйһиссәләм Аллаһы Тәгаләдән риваять кылган:

«...Мин аны ярата башлаганчы Минем бәндә Миңа өстәмә гыйбадәтләр ярдәмендә якынаячак. Мин аны яраткач, ул ишетә торган колак, ул күрә торган күз, ул тота торган кул, ул йөри торган аяк булачакмын. Ул Миннән берәр нәрсә сораса, Мин һичшиксез аны бирәм; Миннән ярдәм сораса, ярдәм итәм; Миңа дога кылса, догасына җавап бирәм!» (Бухари).

**ГАБДРАХМАН ХӘБИБУЛЛИН**

# Сорау-җавап

**–Бер хәдис ишеткәнем бар. Анда, әгәр бер мөселман икенчесенә, син кәфер, дисә, ул үзе кәфер була, диелгән. Әгәр дә ире хатынын кәферлектә гаепләсә?**

–Сез: «Кем үзенең мөселман кардәшенә, кәфер, дип әйтсә, шуларның берсе кәфер булачак»,–дигән хәдисне күз уңында тотасыздыр. Никах темасында, әгәр ир белән хатынның берсе исламнан чыкса, берникадәр вакыттан соң, аларның никахлары өзелә, диелгән. Әлеге принцип бирелә туры килми, чөнки хәдистә кәферлеккә төшү турында түгел, ә әлеге гамәлнең гөнаһлы булуы турында сүз бара.

**–Имам артыннан намазны ничек укырга? Җәмәгать намазы дәресләрендә имам Коръән укыганда эчтән булсын яки тавыш белән, аның артыннан кабатларга ярамый, диелгән. Бу җәмәгать белән укыганда 3, 4 рәкагать фарыз намазларында, 1, 2 рәкагать зухр һәм гаср намазларында фатиханы укымаска дигәнне аңлатамы?**

–Әйе, Хәнәфит мәзһәбе буенча, җәмәгать намазында имам тавыш белән яки үзеннән генә укыса да, аның артыннан кабатларга кирәкми. Чөнки аның намазы–артыннан басып торучыларның да намазы булып санала.

**–Соравым исемем белән бәйле. Мин аны үзгәртергә теләр идем. Ләкин сез аның мәгънәсе уңай булган очракта, моны эшләүнең кирәге юк, дип әйтәсез. «Оксана», «Ксения» грек теленнән тәрҗемә иткәндә «ят, чит ил кешесе» дигәнне аңлата. Чиркәүдә бу исемне изгеләр хөрмәтенә кушалар. Бу исем, минемчә, холкыма туры килми. Бәлки миңа аны алмаштырыргадыр? Оксана.**

–Исем без аны уңышсызлыкларда сәбәпче дип уйлый башлаганчы, безнең тормышыбызга тәэсир ясамый. Әгәр дә инде үзгәртәсегез килсә, сез моңа хаклы.

**–Мин үземнең танышыма карата ямьсез гамәл кылдым. Бу начарлыгымны матди рәвештә капладым. Гомумән, без моны оныткан идек. Минемчә, барыбер хәзер башкалар минем турында начар уйлый. Һәм мин моңа бик тә оялам. Танышларым минем белән аралашса да, аларның миңа карата үзгәргән мөнәсәбәтен тоям. Хәлләрне уңай якка үзгәртер өчен нәрсә эшлим икән? Азамат.**

–Аллаһ Мәрхәмәтле, Шәфкатьле, Гафу итүче. Аның кичерәчәгенә шикләнмәгез. Үпкәләткән кешегездән гафу соравыгыз, матди рәвештә гаебегезне каплавыгыз бик тә мөһим. Ә сезнең турында начар фикердә булучыларга игътибар итмәгез. Зур гөнаһлардан сакланырга тырышып, алга барыгыз. Танышларыгызның сезнең хактагы фикерләрен үзгәртер өчен, сезгә үз эшләрегез белән шөгыльләнергә, уңышлы гына авырлыкларны җиңәргә, максатларга ирешү, ягъни башкалар алдында алдагы елларда уңышларыгызны күрсәтә белү кирәк. Һәм әйләнә-тирәдәгеләргә игътибар итмәгез. Бу як-якка бик зур әһәмият бирмичә, тиз генә куелган максатларга ирешергә ярдәм итәчәк.

**Сорауларга җаваплар umma.ruдан алынды**

# Яулыклы кыз...

**(Дәвамы, Башы 2нче биттә.)**

**Кояшлы Зилә, 16 яшь. Киров өлкәсе, Кильмиз районы:**

-Мин яулыкны 5 класста яптым... Хәтердә әле дә. Беренче сентябрь... Әйе, курку булды. Күрерләр, күргәч, көләрләр... башкалар кебек булмау җиңел түгел. Хәзер уйлыйм: нәрсәгә нигезләнгән булган бу курку? Бигрәк бала идем шул әле ул чакта. Бик күпне аңламый идем. Класс минем бердәнбер җылы урыным, мине анда аңлыйлар иде. Укучылар яхшы мөнәсәбәттә булдылар. Безне хөрмәт иттеләр. Минем арттан ук иң якын дустым да яулык япты. Еллар үтә барды... Укытучылар безне үрнәк итеп куйдылар. Әлхәмдүлиллаһ. Бүгенге көндә “Мөхәммәдия”дә укыйм. Монда мин яулык япкан өчен оялу хисеннән арындым. Хәзер шушы яулыклы кызлар арасында үземне бәхетле тоям. “Мөхәммәдия”дә үземне шәхес буларак та ачтым. Аллаһның рәхмәте булсын әби белән бабайга, алар миңа шундый гүзәл ислам тәрбиясе бирделәр. Әни мине яратырга, ә әти иркен уйларга өйрәтте. Шундый якын кешеләр бүләк иткән Аллаһка чиксез рәхмәтләр булсын !

**Тахмина, Үзбәкстан:**

-Гаиләбез миңа 4 яшь булганда исламга килде. Шушы вакыттан алып әти белән әни миңа Коръән сүрәләре һәм гарәп әлифбасы өйрәтә башладылар. Кечкенәдән үк 18 сүрә белә идем. 6 яшемдә мәктәпкә укырга кердем. Уку динемне өйрәнүдән аерып торды. Мәктәп предметларына кереп баттым. 5 класста урамда яулык ябып йөри башладым, әмма мәктәптә сала идем. Оялдым. Хәзер уйлыйм: ”Нәрсә ояты бар?” Шәригать буенча инде миңа гаурәт җирләремне каплап йөрергә кирәк булса да, бу елларда мәктәптә шулай йөрүемне дәвам иткәнмен. 8 класс. Уку елы башы. Октябрь аенда әтием аварияга очрады. Ай буе комада ятты. Ноябрь аеда гаиләне бердәнбер туендыручыбызны югалттык. Әтинең үлеменнән соң яулык яптым. Нишләп иртәрәк кимәдем?! Әтинең боларны күрмәве миңа бик тә кызганыч. Мәктәптә бөтенесе дә шок хәлендә иделәр, бөтенесе дә моның траур вакыты, яулыгын салыр дип уйладылар. Бер ай дәвамында укытучыларның берниндиди тавыш-тыны чыкмады, кисәтү дә ясамадылар. Шуннан соң мәктәп директоры үзенә чакыртып, мәктәпкә болай йөрергә ярамый дип, лекцияләр укый башлады. Укытучылар дәрестә еш кына кисәтүләр ясадылар. Күпләр көлде. Ә классташларым һәрвакыт мине яклый килделәр. Директор мәктәптән куу белән янады. Мин шуннан соң яулыкны чөеп кенә яба башладым. Мәктәпне тәмамлагач, кая укырга керергә микән дип баш ваттым. Интернетта “Мәдрәсә” дип җыйдым. Анда дөньядагы бөтен мәдрәсәләр дә чыктылар. Беренчеләрдән булып Казан мәдрәсәләре тора иде. “Мөхәммәдия” сайтына кердем. Берничә сорау биреп, шуларга җавап алдым. Бүгенге көндә “Мөхәммәдия” шәкертемен. Әлхәмдүлиллаһ, мин мөселманмын һәм моның белән бик тә горурланам.

**СӘМБЕЛ ШӘРИФУЛЛИНА.**

**“Мөхәммәдия” шәкерте, (КФУ студенты.)**

**БЕЛДЕРҮЛӘР**

*Мәдрәсә базасында атнаның һәр ялында балалар өчен әхлак дәресләре алып барыла. Укуларга рәхим итегез.

*Мәдрәсә бинасында ислам атрибутикасы кибете эшли. (Коръән китаплары, шамаилләр, тмин майлары, дисбеләр, дини китаплар, түбәтәйләр һ.б.)

*Мәдрәсә базасында таныштыру бүлеге эшли. Тел. 89625504168, 89372991485

Балага исем кушу, никах уку һәм башка дини мөрәсимләрне үткәрү. Мамадыш мәдрәсәсе, М. Җәлил ур 8/28), тел: 89172802391

*Намаз, Коръән укырга, дин гыйлемен өйрәнергә теләгән һәр кешене мәдрәсәдә оештырылган кичке уку курсларына чакырабыз.

*Мамадыш мәдрәсәсе фәкыйрь–мескеннәргә, ятим балаларга тарату өчен кулланылган киемнәр кабул итә.

*Мәдрәсә базасында Ислам диненә караган сорауларга җавап бирү хезмәте

Белешмәләр өчен телефон: 89172802391

*Мәдрәсә “Бер айда намаз укырга өйрән” түгәрәгенә укучылар җыя, Белешмәләр өчен телефон: 89372991485

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Хәбибуллина Э.Р.**
**Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Җаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.**
**Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета “Татмедиа” ААҖнең Мамадыш муниципаль районы”Нократ” мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 100 данә.**